Һонәр сайлау жаваплы эш. Бүгенгесе кондә һонәр турында бик күп сойләп була. Чонки замана үзгәргән саен, доньяга карашыбызны да үзгәртәбез. Ни очен дисезме? Хезмәт базарына күз салсан, анда бүген белгечлекләрнен ниндие генә юк! Замана алга атлаган саен, аларнын торләре дә арта бара. Укучыга сайлау момкинчелеге дә зур, ә кайвакытта, югалып та калучылар була. “Кайсы һонәрне сайласам, отышлырак булыр икән?” – дигән сорауларга жавап таба алмыйча еш кына тошенкелеккә дә бирелүчеләр була. Бу очракта әти-әниләр һәм мәктәп ярдәмгә килә. Аларнын акыллы кинәшләре һәрвакыт булыша. Яраткан һонәренне таба алу ул – зур ачыш. Һонәрләрнен кайсын гына алсак та, аларнын һәрберсе жәмгыятебез очен бик кирәкле. Һонәре булган кешенен жирдә һәрвакыт үз урыны, үз юлы була. Үзен яраткан һонәр буенча китү - олы бәхет ул. Бу - куелган максатка ирешү дигән сүз. Шуна һонәр сайлауга мәктәп зур игътибар бирә. Ел саен укучыларны һонәр сайлау юнәлешендәге «Белгечләр шәһәре» («Город мастеров») чарасы Рузаевка районы Татар Пешлә гомуми белем бирү урта мәктәбе үткәрә. Быел да шулай. Бу профориентацион эшнен топ максаты - укучыларны практик рәвештә һонәр белән таныштырып, хезмәт профессиясенә кызыксыну уяту. Проект кысаларында укучылар, эшче профессияләр доньясына кереп чумалар, беренче тапкыр бу һонәрне үзләренә үлчәп карыйлар, кочләрен сыныйлар, белмәгән нәрсәләрен үзлә-штерәләр. Барысы да, һичшиксез, киләчәктә һонәрләрен дорес сайларга булышыр. Максатны тормышка ашыру очен, Пешлә мәктәбендә торле хезмәт кешеләре, һонәр осталары мәй-данчыклары булдырдылар. Укучыларда зур кызыксыну «Тәм-том империясе» мәйданчыгы уятты; шулай проектны башлап жибәрделәр. 9-10нчы сыйныф житәкчеләре Сания Спартак кызы Саляева белән Альфия Шихап кызы Альшина һәм мәктәп пешекчесе (повары) Ильмира Шагидулла кызы Баймашкина татар халык ашларын пешерү һәм тортларны бизәү буенча мастер-класслар үткәрделәр.
Ильмира Шагидулла кызы гомер буе яратып повар булып эшли. Хезмәт биографиясен башта Рузаевка ашханәләренен берсендә башлап жибәрә, ә мәктәптә ашханә ачылгач, алты елдан артык инде, топ пешекче буларак эшли. Ул укучыларын тәмле ризыклар пешереп сыйларга тырыша. Анын ашлары укучыларга ошый – тәмләп ашыйлар, добавкалары белән бергә. Тагы, балаларны яратканга, укучылар аны да яраталар. «Пешекче эше һонәр түгел, ә сәнгать», диләр. Монын шулай булуы беребезгә дә сер түгел. Ильмира Шагидулла кызы гади генә ризыкны да үзенчәлекле итеп бизи һәм табынга бирә белә. Мисалга, пәрәмәчнен кырыйларын матур бизәкләр белән эшләп пешерә һәм остәлгә матур иттереп куя. Шулай, Ильмира Шагидулловна унынчы сыйныф

укучылары белән vткәргән мастер-классында торле милләт халкы яратып ашаган татар пәрәмәчләрен пешерделәр һәм торт әзерләделәр. Ә тугызынчы сыйныфлылар бvген кvбебез яраткан пицца белән «Шарлотка» пирогын Ильмира апалары белән бергә пешерергә ойрәнделәр. Укучыларда кызыксыну бар, теләк бар - булдырдылар. Шулай булгач, пешекче профессиясен сайлаучылар да булыр дигән ышаныч туа.
Проектнын икенче мәйданчыгы - «Чибәркәйләр салоны» («Салон красоты»). Анда 6-8 сыйныф укучылары чәч vpv буенча ярышачаклар. Кем тиз һәм матур vpә. Андыйлар да табылыр дип ышанабыз. Тагы бәйрәм прическалары эшләп карарлар.
Мастер-классларны шулай ук сыйныф житәкчеләре, белгечләр белән бергә, оештырырлар. Менә шулай бергәләп, «Белгечләр шәһәре» проектындагы чаралар ярдәмендә, Татар Пешлә мәктәбе укучылары һонәр нечкәлекләренә ойрәнәләр.

Наилә Насырова